«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары

2017 елның 25 сентябрендәге №48

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү һәм уздыру турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, “Җирле референдум турында” Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы ИскеБарышавыл җирлеге Уставының 15 статьясы, “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында” Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 25 сентябрендәге 6 номерлы карары, Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлегенең референдум уздыру инициативасы хакында” Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2017 елның 19 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2018 елда үзара салым кертүгә сез 500 сум күләмендә килешәсезме, моңа көндезге бүлектә белем алучы студентлар керми һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән беррәттән:

**- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак ташлы өслекле юлны ремонтлау: Иске Барыш авылы, Родники ур., Мәктәп ур., у. Елга урамы; Кыртапа ур., Родниковая ур., Мирная ур., Яшьләр ур., Мәктәп ур.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Барыш ав., Үзәк ур., 15 й.

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кыртапа йорт, Мәктәп ур., 10 й.

шулай ук «Идел таңнары» газетасының рәсми сайтында («Идел таннары») бастырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Иске Барыш авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Иске Барыш
авыл җирлеге Советы рәисе И.Р. Зиганшин